ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

22.10.2020 | 14

с. Кильдеево

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004нче елның 24нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020нче елның 20нче октябрендәге 1нче номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Килди авыл җирлегенең Башкарма комитеты

карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам .

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы Бурдин В. М.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан
муниципаль районы
Килди авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020нче елның 22нче
октябрендәге 14нче
номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү 2021нче елның 1нче гыйнварыннан 2021нче елның 31нче мартына кадәр гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына гражданнардан алынган үзара салым акчалары керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашырып, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының (https://uslugi.tatarstan.ru/) ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.